**Татарстан Республикасы**
**Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы**

# КАРАР

**16 октябрь 2020 ел** **№ 14**

**Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советының «Җир салымы турында» 2016 елның 18 апрелендәге 25 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. «Җир салымы турында» Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советының 2016 елның 18 апрелендәге 25 номерлы карарына (Нурлат шәһәре Советының 2016 елның 26 сентябрендәге 34 номерлы, 2017 елның 02 сентябрендәге 54 номерлы һәм 2019 елның 18 июнендәге 114 номерлы, 2019 елның 17 декабрендәге 128 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләре һәм өстәмәләре белән), карарның 2 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«2. шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган, бакчачылык яисә яшелчәчелек, шулай ук «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата - 0,3 %;».

2. Әлеге карар, рәсми басылып чыккан көннән соң бер айдан да иртәрәк булмаган вакыт эчендә, 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга, әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, шул исәптән Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Нурлат шәһәре Советы рәисе А.С. Әхмәтшин